**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
НОВОШЕШМИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
ул. Советская, д.80,
с. Новошешминск,423190

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯҢА ЧИШМӘ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**
Совет урамы, 80,
Яңа Чишмә авылы,423190

тел.: (8-84348) 2-31-00, факс: (8-84348) 2-20-22, chishma@tatar.ru

КАРАР

2021 елның «05» апреленнән № 165

Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы территориясендә Россия Федерациясенең дәүләт урман фонды җирләренә һәм физик һәм юридик затларның шәхси милкендәге җирләргә кермәгән яшел үсентеләрне кисү тәртибе турындагы Нигезләмәне раслау хакында» 15.03.20021 ел, № 120 карарына үзгәрешләр кертү турында

Россия Федерациясе Урман кодексы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законы, «Әйләнә-тирә мохитне саклау турында» 2002 елның 10 гыйнварындагы 7-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Татарстан Республикасының Яңа Чишмә муниципаль районы территориясендә, Россия Федерациясе дәүләт урман фонды җирләренә һәм физик һәм юридик затларның шәхси милкендәге җирләргә кермәгән, Татарстан Республикасының Яңа Чишмә муниципаль районы территориясендә яшел үсентеләрдән рациональ файдалану, саклау һәм яңадан җитештерү максатларында, Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитеты карар бирә:

1. Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы территориясендә Россия Федерациясенең дәүләт урман фонды җирләренә һәм физик һәм юридик затларның шәхси милкендәге җирләргә кермәгән яшел үсентеләрне кисү тәртибе турындагы Нигезләмәне раслау хакында» 15.03.20021 ел, № 120 карарына түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1.1. 3.2 пунктны түбәндәге эчтәлекле абзац белән тулыландырырга:

«Рөхсәт Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына салымнар, җыемнар һәм башка түләүләр буенча бурычлар булмаган очракта бирелә».

2. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат – телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru һәм Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының рәсми сайтында http://novosheshminsk.tatarstan.ru бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең инфраструктур үсеш буенча урынбасарына йөкләргә.

Җитәкче Р.Р. Фәсахов